**Килешенгэн:**
Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты житэкчесенен мэгариф буенча урынбасары
_____________ Л.Н.Маняпов

**Кабул ителеде:**
Педагогик кинэшмэ
Утырышында килешелгэн
29.08.2016 ел
Протокол № 1

**Расланган:**
Яна Иглай авылының 31 нче номерлы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе
Модир:
_____________ А.М.Маняпова
23.08.2016 ел.

# Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яна Иглай авылының 31 нче номерлы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе 2016-2021 нчы уку елларына

# Үсеш программасы

**2016**

# Эчтәлек

**Программаның паспорты .......................................................................................3**

**Аңлатма язуы...............................................................................................................6**

**I.Белем бирү учреждениесе турында мәгълүмати белешмә .......................................... 7**

**II.Үсеш программасының аналитик нигезләмәсе………………..………………………11**

**III.Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе үсешенең концептуаль нигезләре...............11**

**IV. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең үсеш стратегиясе ...................................12**

**V.Программаны тормышка ашыру этаплары................................................................13**

**VI. Программаны тормышка ашыру буенча эшчәнлек планы....................................14**

VI.1.**Программа белән тәэмин ителеш, методикалар, технологияләр ………………..14**
VI.2.**Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен информация белән тәэмин итү………..16**
VI.3. **Сәламәтлек. Сәламәтлек саклау технологияләре....................................………........17**
VI.4. **Белем бирү эшчәнлегенең иминлеге...............................……………………………..18**
VI.5. **Кадрлар политикасы..............................................…………………………….....19**

**Кушымта:**

**Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесен тәмамлаучының социаль портреты 21**
**Балалар бакчасы педагогы моделе…...……………………………22**

ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яна Иглай авылының 31 нче номерлы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе 2016-2021 нчы уку елларын Үсеш программасы (Программа) |
| **Программаның статусы** | Үсешнең максатчан программасы идеологиясен нигез итеп алган һәм эшчәнлектә инновацион режимга күчүчебюджет учреждениесенең норматив документы |
| **Программаны төзүчеләр** | Яна Иглай балалар бакчасының мөдире А.М.Маняпова |
| **Программаны үтәүчеләр** | Яна Иглай балалар бакчасы педагогик коллективы, әти-әниләр җәмәгатьчелеге, социаль партнерлар. |
| **Программаны эшләүнең фәнни-методик нигезләре** | Программаны төзүдә кулланылды:<br>– Мәгариф үсешенең федераль программасы материаллары;<br>– Россия Федерациясенең «Белем турында»гы законы;<br>- Постановление Правительства РФ от 27 октября 2011 года N 2562 «Об утверждении Типового положения о дошкольном образовательном учреждении».<br>– Приказ Министерства образования и науки РФ от 23.11.2009 г № 655 «Об утверждении и введении в действие ФГОС к структуре основной общеобразовательной программы дошкольного образования»;<br>– Приказ Министерства образования и науки РФ от 20.07.2011 г № 2151 «Об утверждении ФГОС к условиям реализации основной общеобразовательной программы дошкольного образования»;<br>– Постановление кабинета Министров Республики Татарстан от 22.02.2014 г. № 110 «Об утверждении программы «Развития образования и науки Республики Татарстан на 2014-2025 г.г. |
| **Программаны тормышка ашыру срогы:** | Башлана: 01.09.2016<br>Төгәлләнә: 31.05.2021 |
| **Программаны тормышка ашыру этаплары** | **1 этап** – Мобилизация- оештыру: булган ресурсларга диагностика уздыру, Программаның төп чараларын барлап чыгу, аларны тормышка ашыру өчен тиешле шартлар тудыру, Программаны үтәргә керешү.<br>Бурычлары:<br>*МБМБУның эшчәнлегенең торышын анализлау.<br>* Хокукый-норматив базаны өйрәнү.<br>*Тәрбияләнүче балаларның сәламәтлек торышын анализлау.<br>*Балаларның үсеш торышын һәм педагогларның квалификация дәрәҗәсен анализлау.<br>МБМБУныңбелем бирү эшчәнлеге торышын ФДББС һәм укыту-методик комплектларга туры килүен анализлап, белем бирү процессына кертү.<br>*МБМБУның матди-техник базасын анализлау.<br>*Татарстан Республикасында МБМБУларында балаларны |

| | |
|---|---|
| | ике дәүләт теленә өйрәтү буенча ата-аналар фикерләрен өйрәнү.<br>*2 этап – Эксперт – тикшерү: Программаның стратегик мәсьәләләрен тормышка ашыру.<br>*Программаны тормышка ашыру.<br>*Аралык нәтиҗәләрен барлап бару.<br>*Белем бирү процессында укыту-методик комплектларны тормышка ашыру.<br>*Балаларның Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә сөйләшүен тәэмин итү.<br>*Балаларның тулы куәтле үсешен тәэмин итү максатларында, гаиләләр белән тыгыз элемтәләрне булдыру.<br>**3 этап** – гомумиләштерү – йомгаклау: йомгак ясау һәм эшчәнлек нәтиҗәләрен Программаны тормышка ашыруның төп юнәлешләре буенча максатлары һәм бурычларына тәңгәл килүен карау, нәтиҗәләрне игълан итү һәм алдагы чор өчен Үсеш Программасы булдыру.<br>*Үсеш программасын тормышка ашыруда МББУның тәҗрибәсен өйрәнү һәм туплау.<br>*МБМБУның яңа үсеш программасын эшләү.<br>*Проблемаларны ачыклау.<br>МБМБУның үсеш программасы үтәлешенә отчет бирү. |
| **Программаның максаты** | Мәктәпкәчә яшьтәге балалар яшәеше өчен уңайлы шартлар тудыру, ТРның ике телен дә өйрәтү, шәхес культурасы нигезләре өчен җирлек тудыру, яше һәм шәхси үзенчәлекләре нигезендә баланың төрле яклап үсешенә ярдәм итү, заманча җәмгыятьтә яшәүгә һәм мәктәптә укуга әзерләү, баланың тормыш иминлеген тәэмин итү.<br>*Балаларның белем алу сыйфатын күтәрү.<br>*Тәрбияләнүче балаларның танып белү, социаль-шәхси, әдәби-эстетик һәм физик үсеше сыйфатын күтәрү.<br>*МБМБУда тәрбияләнүче балаларның сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген күтәрү.<br>* Педагогларның укыту-методик комплектлар буенча эшләү алымнарын өйрәнүен тәэмин итү. |
| **Проблемалар** | *Татар гаиләләрендә туган телнең әһәмиятлелеген югалту.<br>*Балалар тарафыннан ике дәүләт телен дә белмәү.<br>*Ата-аналарның белем бирү процессына кушылырга әзер булмавы.<br>*Заманча белем бирү технологияләрен куллану аша педагоглар эшчәнлегенең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттыру зарурлыгы.<br>*Бакчага килүче балаларның сәламәтлегенең объектив начарлануы алар тарафыннан белем алуның сыйфаты кимүдә сизелә. |
| **Программаның төп бурычлары** | *Балаларның сәламәтлеген ныгытуга комплекслы килүне, аларның психик-эмоциональ иминлеген тәэмин итү, балалар белән эшләүдә профилактик сәламәтләндерү технологияләрен гамәлгә кертү.<br>*ТРның ике дәүләт телен өйрәтү буенча укыту-методик |

| | |
|---|---|
| | комплектларын гамәлгә кертү өчен шартлар тудыру.<br>*Әйләнә-тирә дөньяга, туган гаиләсенә, туган йортына, туган җирлегенә, Туган иленә, төрле милләт кешеләренә уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>*Балаларда сәламәт тормыш рәвеше белән яшәү зарурлыгы булдыру, үз сәламәтлеге өчен җаваплылык хисе тәрбияләү.<br>*Мәктәпкәчә яшьтә белем бирү һәм башлангыч гомуми белем бирүдә дәвамчанлыкны тәэмин итү.<br>*Балаларның физик һәм психик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту.<br>*Балаларда гражданлык хисләре, кеше хокукларына һәм кеше ирегенә хөрмәт, табигатькә, Ватанга, гаиләгә хөрмәт тәрбияләү.<br>*Психолог ярдәме белән балаларга белем бирү эшчәнлегендә барлыкка килгән кимчелекләрне бетерү өстендә эшләү.<br>*Балаларның тулыкуәтле үсешен тәэмин итү максатларында гаиләләр белән элемтәләрне ныгыту.<br>*Белем бирү һәм тәрбия эчтәлеген, шартларын, технологияләрен модернизацияләү юлы белән белем бирү процессын яңарту.<br>*Педагогларның һөнәри осталыгын һәм инновацион культурасын камилләштерү.<br>*Учреждениедә идарә системасын оптимальләштерү. |
| **Программаны тормышка ашырудан көткән нәтиҗәләр** | Балаларның белем алу сыйфатын күтәрү.<br>*тәрбияләнүче балаларның танып белү, социаль-шәхси, әдәби-эстетик һәм физик үсеше сыйфатын күтәрү.<br>*МБМБУда тәрбияләнүчеләрнең сәламәтләндерү нәтиҗәлелеген күтәрү.<br>* Педагогларның укыту-методик комплектлар буенча эшләү ысулларын һәм алымнарын өйрәнүен тәэмин итү.<br>*ТРда балаларның ике телдә аралашулары өчен шартлар тудырылачак.<br>*Туган гаиләгә, төбәккә, Ватанга, әйләнә-тирә мохиткә, төрле милләт вәкилләренә хөрмәт тәрбияләү.<br>*Балаларда сәламәт тормыш рәвешенә, үз-үзләренең сәламәтлегенә җаваплылык хисе тәрбияләү.<br>*Мәктәпкәчә һәм башлангыч белем бирүдә дәвамчанлык.<br>*Балаларның физик һәм психик сәламәтлеген саклау һәм ныгыту.<br>*Балаларга хокук белемнәрен бирү, патриотизм, туган төбәккә мәхәббәт тәрбияләү. Кеше хокукларын хөрмәтләү.<br>*Психолог ярдәме белән балаларга белем бирү эшчәнлегендә туган кимчелекләр өстендә эшләүне камилләштерү.<br>*Гаиләләр белән элемтәләрне ныгыту. |
| **Программаның өстенлекле юнәлешләре** | Мәктәпкәчә белем бирүнең сыйфаты белән идарә итү.<br>*Методика, технологияләр белән программаны тәэмин итү.<br>*Белем бирүне информатизацияләү.<br>*Толерантлылык.<br>*Сәламәтлек саклау технологияләре.<br>*Белем бирү процессының иминлеге. |

| | |
|---|---|
| | *Кадрлар политикасы.<br>*Дәүләти-җәмгыять үзидарәсе.<br>*Партнер оешмалар. |
| **Программаны финанслау чыганаклары** | Муниципальбюджет финанславы |
| **Программаны тормышка ашыру белән идарә итү тәртибе** | Программа белән идарә итү һәм төзәтмәләр кертү хезмәт коллективы Киңәшмәсе тарафыннан башкарыла |

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Россия мәгариф системасын модернизацияләүнең заманча ориентирлары – яраклаштырылу, сыйфат, нәтиҗәлелек - мәктәпкәчә белем бирү оешмалары алдында югары таләпләр куя. Бүгенге көндә Россиядә мәктәпкәчә яшьтәге белем бирүне күчеш халәтендә дип бәяләргә мөмкин. Балалар бакчасы конкуренциягә сәләтле һәм алдынгы булырга тиеш, ә бу педагогика өлкәсендә прогрессив технологияләрне, методикаларны иҗади эзләүдә һәм һөнәри осталыкны даими үстерү режимында гына була ала.

Мәктәпкәчә оешма белән идарә итү системасын заман таләпләренә туры китереп яңарту теләге әлеге үсеш программасын эшләргә этәрде. Әлеге программма мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең үсеш стратегиясен билгели һәм аны тормышка ашыру буенча эшчәнлекне билгели. Программаны төзегәндә түбәндәге принципларга таянып эш ителде:

- Максатчан якын килү, планлаштыру һәм планнарга үз вакытында корректировкалар кертү (бөтенлек, конкретлылык, активлык, сыгылмалылык);
- Белем бирү процессында катнашучыларның информацион компетентлылыгы.

Татарстан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яна Иглай авылының 31 нче номерлы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесенеңүсеш программасын тормышка ашыру бакчаның абруен күтәрүдән тыш, педагогик коллективның белем һәм тәрбия өлкәсендәге казанышларын, эти-әниләрнең һәм балаларның уңышларын, казанышларын күрсәтергә ярдәм итә. Бу үз чиратында, педагогларның, эти-әниләрнең һәм балаларның нәтиҗәле бердәм эшчәнлегенә уңай шартлар тудыруны таләп итә.

Программа үтәлеше нәтиҗәсе - балалар бакчасында белем биру сыйфатының күтәрелүе, яңалыкларның киң кулланылуы, югары нәтиҗәлелек.

Программа балалар бакчасында белем һәм тәрбия процессының үсешенә, мәктәпкәчә мәгарифнең милли компонентлар һәм дәүләт стандартларын тормышка ашыруына, норматив һәм оештыру документлар кабул итү өчен нигез булып тора. Программа максатчан педагогик һәм идарә итү эшчәнлеге өчен барлык бакча хезмәткәрләренә җәмгыять үсешенең яңа шартларында эти-әниләр һәм халык белән хезмәттәшлек итү өчен мөмкинлекләр ача.

Программа 5 проекттан тора.

**Программаның бурычлары:-балалар бакчасында үстерешле тирәлек булдыру; -педагогларның профессиональ осталыкларын үстерү;-оешманың белем бирү, инновацион һәм финанс-икътисадый эшчәнлеге белән идарә итү системасын яңарту; - белем һәм тәрбия процессының сыйфатын күтәрү; - һәр баланың нәтиҗәле үсешен тәэмин итү; - Мәктәпкәчә мәгарифнең һәркем өчен мөмкин булуыикътисадый шартларыннан аңлап төзелә.**

**Программа 3 төп функцияне үти:**

**- балалар бакчасының үсеш стратегиясен билгели;**

**- эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләрен күрсәтә;**

**- бөтен эшчәнлекне ахыргы нәтиҗәгә юнәлтә.**

**Программа түбәндәге принципларга таяна:**

- **Интегральләштерү**
- **Гуманлылык**
- **Мавыгучанлык**
- **Вариативлык**

## I.МӘГЪЛҮМАТИ БЕЛЕШМӘ

| | | |
|---|---|---|
| МБМБУның кыскартылган исеме | “31 нче номерлы Яна Иглай авылы балалар бакчасы” | |
| МБМБУның тулы исеме | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яна иглай авылының 31 нче номерлы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе | |
| Тип | Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе | |
| Төре | Балалар бакчасы | |
| Оештыручы | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | |
| Оештыру-хокук формасы | Муниципаль | |
| Авыл | Яна Иглай | |
| Үзидарә органы (Устав нигезендә) | Коллективның гомуми җыелышы | |
| Идарә итүче система | Мөдир | Маняпова Айгол Минзахид кызы |
| Телефон | 8(84345) 3-36-73 | |
| Электронная почта | | |
| Адрес | 423117, Татарстан Республикасы,Нурлат районы,Яна Иглай авылы, Чапай урамы, 23 нчы йорт; | |
| Устав | Регистрация органы: МРИ МНС России № 16 по РТ 29июля2016г.<br>Расланган:Татарстан Республикасы Нурлатмуниципаль районы Башкарма комитеты карары,19.07.2016ел.№587 | |
| Лицензия | Серия 16 Л01 № 0001857 Регистрация номеры № 6063от 23марта 2015 года<br>Приказ МО иН РТот 23 марта 2015 года, № 1769/15Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | |

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яна Иглай авылының 31 нче номерлы мәктәпкәчә белем муниципаль бюджет учреждениесе 1986нче елда сафка бастырылган.

Оештыручы:Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты.

Яна Иглайбалалар бакчасыүз эшчәнлеген Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының "Мәгариф турында"гы Законы, “Мәктәпкәчә учреждение турында типовое положение”, Оештыручы һәм МБМБУ арасындагы килешү, МБМБУ Уставына нигезләнеп башкара.

Балалар бакчасының эш режимы – 10,5 сәгать.

**Материаль база.**Белем бирү бурычларын тормышка ашыру максатыннан балалар бакчасы татар почмагы, рус теле почмагы һәм укыту-методик комплектлар белән тулыландырылган.

Балалар бакчасында төркемдә 13 бала тәрбияләнә.

Бакчаның балаларга белем һәм тәрбия бирүдә төп юнәлешләре:

- милли региональ компонентка таянып, милли мәдәниятне белүче һәм дәвам итүче шәхес тәрбияләү;

- балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру;
- үстерешле тирәлек булдырып, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү;
- халык педагогикасы принципларына нигезләнеп, яңа педагогик алымнар кулланып, балаларга әхлак һәм патриотик тәрбия бирү;
- экологик күнекмәләр формалаштыру;
- балалар бакчасы һәм гаиләнең хезмәттәшлеген арттыру, инновацион методлар кулланып, гаилә белән эшләү.

Балалар бакчасының төп бурычлары итеп балаларның сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту, физик һәм психик куркынычсызлыкларын тәэмин итү; физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатларын үстерү өчен эшчәнлектә уңай шартлар тудыру;
төрле эшчәнлектә мәктәпкәчә яшьтәге балалар шәхесенең социаль һәм психологик сыйфатларын үстерүгә ярдәм итүче предметлы-пространство тирәлеге булдыру;
ата-аналар белән бердәм эшчәнлектә педагогларның профессиональ осталыгын камилләштерү алынды.

**Әйләнә-тирә мохит.**Безнең балалар аерым ике катлы бинада урнашкан. Бакчабыз 25 урынга исәпләнелгән, 13 бала йөри. Хезмәт күрсәтү сферасында бакчабыз тотрыклы урын алып тора.Якын тирәсендәмедецина пункты, китапханә, Яна Иглай мәдәният йорты урнашкан. Педагогик эшчәнлекне оештыруда бу оешмаларның якын булуы ярдәмләшеп, кулга-кул тотынып эшләргә мөмкинлек тудыра.

**Кадрлар белән тәэмин ителеш.** Бакчада педагогларның белемнәрен күтәрү буенча даими планлы эш алып барыла, инновацион активлыклары бәяләнә. Тәрбияче КМО, РМО ларга йөреп, тәрбия- белем бирүнең актуаль проблемалары буенча тәҗрибә уртаклаша.

**Белем бирү процессы.** Балалар бакчасында белем бирү процессы Н.Е.Веракса, Т.С. Комарова, М.А. Васильева редакциясендә чыккан «Туганнан алып мәктәпкә кадәр”. мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы,Р.К. Шаехованың «Төбәкнеңмәктәпкәчә белем бирү программасы» нигезендә алып барыла.

Методик кулланмалар:

Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 2-3 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2015;
Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 3-4 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек Казан “Фолиант”, 2015;
Ф.В.Хәзрәтова, З.Г.Шәрәфетдинова “Туган телдә сөйләшәбез” 4-5 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2015;
З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева “Туган телдә сөйләшәбез” 5-7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек, Казан “Фолиант”, 2012;
С.М.Гаффарова, Д.С.Гарипова “Изучаем русский язык” методическое пособие для воспитателей детских садов 4-5 лет, 5-6 лет, 6-7 лет.
С.М.Гаффарова, Д.С.Гарипова “Изучаем русский язык”: программа, методические рекомендации, диагностика, Казань, 2013;
Р.К.Шаехова Мәктәпкәчә балалар әлифбасы: “Авазларны уйнатып” , Казан,2015.
Р.К.Шаехова “Занимательное обучение татарскому языку, Казан, 2015.
К.В.Закирова “Балачак аланы”, балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен хрестоматия, Казан, 2015.
К.В.Закирова “На поляне детства”, хрестоматия для воспитателей детских садов, Казан, 2015.
К.В.Закирова, Л.Р.Мортазина “Әй уйныйбыз, уйныйбыз”, балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма, Казан, 2013;
З.М.Зарипова “Үстерешле уеннар”, Казан, 2013
З.М.Зарипова, А.Х.Габдрахимова “Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге”, Казан, 2013;

К.В.Закирова «Гаиләдә, балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү программасы" , Казан,2005.
Н.Г.Гарипова, Р.С. Эхмэтова "Эйлэнэ-тирэ донья белэн танышу", Казань, 2016,
Р.М.Зиннатова, Л.Э.Грараева"Сурэтлэу хэм кору эшчэнлеге",Казань, 2016,
З.Г. Шэрэфетдинова, И.Ж. Хэбибуллина, Ф.З. Хэзрэтова "Математикага ойрэнэбез", 2016,
В.Г. Гомарова, Ф.Я.Зарипова "Бэйрэмнэр Бэйлэме" Казань, 2005,
К.В. Закирова "Балалар бакчсында эдэп –эхлак тэрбиясе", Казань, 2013

**Укыту-методик комплектлар:**

- татар балаларын ана телендә сөйләшергә өйрәтү - «Туган телдә сөйләшәбез» (җитәкче Хазратова Ф. В.) - методик кулланма, эш дәфтәрләре, күрсәтмә һәм таратма материал;
- татар балаларын рус теленә өйрәтү - «Изучаем русский язык» (җитәкче Гаффарова С.М.) - методик кулланма, эш дәфтәрләре, күрсәтмә һәм таратма материал,балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия, аудио һәм видеоматериал, мультимедиа;
- мәктәпкә әзерлек төркеме балаларын грамотага өйрәтү - «Мәктәпкәчә яшьтәгеләр әлифбасы: авазларны уйнатып» (татар балалары өчен) һәм «Раз – словечко, два - словечко» кулланмасы, автор Шаехова Р. К. - , эш дәфтәрләре, тәрбиячеләр өчен методик рекомендацияләр, тәрбиячеләр һәм әти-әниләр өченметодик кулланма.

  Балалар бакчасында кулланылган программалар мәктәпкәчә яшьтәге балаларда гомуми культура хәзинә үрнәкләре формалаштыру, физик, интеллектуаль һәм шәхси сыйфатлар тәрбияләү һәм балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгытуга юнәлтелгән.

Балалар бакчасында укыту процессын оештыруда заманча формалар кулланыла: бердәм эшчәнлек төркемнәрдә һәм индивидуаль алып барыла. Мондый формаларны куллану тәрбиячегә, белем бирү максатларын, балага якын килеп, аның эшләү дәрәҗәсен, үзләштерү тизлеген исәпләп, төзергә мөмкинлек бирә.

«Инновацион белем бирү технологияләрен куллану аша мәктәпкәчә белем бирү эчтәлеген яңарту» резолюциясе нигезендә 2012нче елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы балалар бакчаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ике дәүләт телен өйрәтү максатыннан яңа укыту-методик комплектлар кулланылышка кертелде.

Педагоглар балаларда кешелеклелек сыйфатлары тәрбияләүгә, табигать доньясына, кешеләргә ихтирам һәм хөрмәт тәрбияләүдә бар тырышлыкларын куеп эшлиләр. Бакча педагогларының яшь буын тәрбияләүдә иң мөһим бурычларның берсе – баланың социаль-шәхси үсеше.

Балалар бакчасында предметлы-үстерешле тирәлекне яңарту процессы бара. Уен һәм дидактик материалның уңайлы һәм урынлы урнаштырылуы балаларга төрле эшчәнлекләр белән шөгыльләнү өчен зур мөмкинлекләр тудыра.

Уен – балаларның төп эшчәнлеге. Уен вакытында булачак шәхеснең нигезләре салына. Бу үзенчәлекне исәпкә алып, төркемнәрдә : «Матурлык салоны», «Супермаркет», «Шифаханә», "Төзүчеләр", "Чэчтарашханэ", "БДД почмагы", ""Конструктлашу","Кибет", "Профессиялэр ойрэну"һ.б.уен почмаклары булдырылды.

Балаларга эстетик тәрбия бирү буенча эшчәнлек тәрбия процессының төрле яклары белән бәйләнгән. Педагоглар балаларда уен, хезмәт эшчәнлегендә матур әдәбият һәм сәнгать әсәрләре аша эстетик зәвык тәрбиялиләр.

Бакчада «Кошлар көне», «Сабантуй», «Нәүрүз», «Әти, әни, мин – спорт гаиләсе», сәламәтлек көннәрен бергәләп бәйрәм итү бик матур традициягә әйләнде.

Балаларның сынлы сәнгатьтә иҗади сәләтләрен үстерүгә зур игътибар бирелә. Классик рәссамнарның әсәрләре белән, халыкларның декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләре белән танышалар.

Нәфасати эшчәнлектә төрле технологияләр, алымнар куллануга, композиция, материал, сюжет сайлауга ирек бирү, балага үз-үзен күрсәтә алуга мөмкинлек бирә, иҗат итү һәм танып белү сәләтен үстерү.

План нигезендә башкарылган максатчан эш нәтиҗәсендә балаларыбыз рухи яктан баедылар, аларның иҗат мөмкинлекләре ачылды, нәфасати эшчәнлекләрдә уңай күнекмәләр формалашты.

**Сәламәтләндерү эше.**

Физкультура-сәламәтләндерү эшен дөрес оештыру нәтиҗәсендә балаларның авыру очракларыкүрсәткече сизелерлек кимеде. Бу тотрыклы күрсәткечнең төп факторы булып яхшы итеп җиһазланган спорт мәйданчыгы булу тора.

Балалар арасында авырулар очракларын киметү максатыннан сезонлы тын юллары авырулары кискенләшкән вакытларда, профилактика чаралары үткәрелә: фитотерапия, поливитаминннар кабул итү, чыныктыру чаралары, үз-үзеңне массажлау, сулыш гимнастикасы ясау. Физик культура эшчәнлегендә баланыңумыртка баганасын дөрес формалашырга ярдәм итәрлек күнегүләр кертелә. Табиблар(педиатрлар) күзәтүендә 5-7 яшьлек балаларның диспансеризация үтүенә зур игътибар бирелә.

**Әти-әниләр белән эш.** Белем бирү процессында катнашучыларның берсе булып тәрбияләнүчеләрнең әти-әниләре (ышанычлы вәкилләр) тора. Алар арасындагы мөнәсәбәт гамәлдәге законга, балалар бакчасы Нигезләмәсенә, әти-әниләр һәм балалар бакчасы арасындагы килешүгә таянып, җайга салына. Әти-әниләр һәм балалар бакчасы арасындагы килешү һәр гаилә белән аерым төзелә, һәм ул баланың бакчада булган вакытында уңай шартлар тудырырга һәм аның индивидуаль үзенчәлеген, мөмкинлекләрен, әти-әниләрнең таләпләрен, теләкләрен исәпкә алып, белем бирү өлкәләренең барлык төрен тәкъдим итүне гарантияли. Безнең балалар бакчасында әти-әниләргә белем бирү процессына, тәрбия чараларына катнашырга, тәрбияче белән балаларның эшчәнлеге барышында, режим моментларына ирекле рәвештә керергә мөмкинлекләр бирелә. Тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре белән традицион формадагы эшләр: консультацияләр, очрашулар, әңгәмәләр, җыелышлар, күрсәтмә информация, публикацияләр тәрбия өлкәсендә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

Хәзерге вакытта җитәкчелекнең, бакча педагогларының, әти-әниләрнең тыгыз элемтәдә булуы, бердәм эшчәнлек алып баруы бигрәк әһәмиятле. Моны тормышка ашыру максатыннан яңа төрэшчәнлек формаларын әти-әниләргә тәкъдим итәбез: күргәзмәләр, бергә оештырган спорт бәйрәмнәре. “Ачык ишекләр көннәре”, әти-әниләр белән балаларның бергә ясаган иҗади эшләр күргәзмәләре. Өлкәннәр белән балаларның бердәм эшләве, аларның дусларча тыгыз элемтәдә булуы, алар арасында уртак кызыксыну булу – балада эмоциональ комфорт тудыра.

Әти-әниләрнең балалар бакчасында көнлек режим, туклану, сәламәтләндерү, белем бирү, күңел ачу эшчәнлекләре, баланың бакчадагы яшәү шартлары, аларның бакчага карата мөнәсәбәте, педагогларның һөнәри осталыклары хакында булган фикерләрен өйрәнгәннән соң түбәндәгеләр ачыкланды: әти-әниләр бакча коллективына, аның җитәкчелегенә ышаныч белдерәләр.

Күпчелек әти-әниләр эш нәтиҗәләре белән кызыксыналар, ләкин гаилә белән бакча арасындагы бердәм эшчәнлекнең әһәмиятен тулысынча аңлап җиткермиләр, шуның өчен дә белем бирү процессына тиешенчә катнашып, кереп китә алмыйлар. Шулай итеп, балаларга белем бирүдә бердәм тырышлыкның көчен аңлап уңай нәтиҗәләргә ирешергә теләүче әти-әниләр белән җитәрлек дәрәҗәдә кызыксынмаган, белем бирү өлкәсенең асылына төшенеп җитмәгән әти-әниләр арасында күпмедер каршылыклар килеп чыга. Бу проблема чишүне балалар бакчасында, гаиләләрдә заманча таләпләргә туры килгән традицион булмаган эш ысулларын кулланып, аларга таянып, дәвамлы рәвештә хәл итәчәкбез. Ә моның өчен тәрбияләнүче балаларның әти-әниләре белән партнерлык мөнәсәбәтне үстерүне үз югарылыгына җиткерергә кирәк.

**Башка оешмалар белән элемтә.** Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе авылның китапханәсе һәм мәдәният йорты белән тыгыз элемтәдә тора. Алар белән хезмәттәшлек итү мәктәпкәчәмәгариф системасына куелган яңа таләпләрдә уңышлы ориентлашырга, үзенең эшчәнлеген психология һәм педагогика өлкәсендәге казанышларны һәм социум

таләпләрен искә алып, вакытында коррекцияләргә мөмкинлек бирә. Мәдәният йортындаүткәрелгән чараларда катнашу балаларның эмоциональ һәм эстетик кичерешләрен баета.

**Эш дәверендә килеп туган кыенлыклар һәм аларны чишү юллары.** Финанслау җитәрлек күләмдә булмау сәбәпле, балалар бакчасының эшен катлауландыра. Әти-әниләр, мәктәп, балаларның ихтыяҗларын өйрәнү өчен күләмле эш башкарылу сорала.Авырлыклар булуына карамастан, мәктәпкәчә оешма үзенең материаль базасын яхшы хәлдә тота һәм тулыландырып тора. Администрация һәм педагогик коллективның тырышлыгы балалар бакчасы имиджын саклап калу, тагы да югары үрләргә күтәрүгә юнәлтелгән.

**Балалар бакчасы җитәкчесе алдында торган мөһим мәсьәләләр:**

- педагогик коллективны берләштерү, туплау;
- иҗади эзләнүне стимуллаштыру;
- педагогларга инновацион үзгәрешләргә уңай мөнәсәбәт һәм хезмәттәшлек итү теләге уяту өчен булышлык итү;
- коллективта бердәм иҗади эшчәнлек өчен уңайлы тирәлек булдыру.

## II. ҮСЕШ ПРОГРАММАСЫНЫҢ АНАЛИТИК –ПРОГНОСТИК АЛШАРТЛАРЫ

Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең 2014-2019 елга үсеш программасын төзүнең алшартлары булып дәүләтнең белем бирү сәясәтендәге үзгәрешләр, 2020 елга кадәр белем бирү системасын модернизацияләү һәм балалар бакчасының яңа Типовое положениесен кабул итү тора. Максатлы күрсәтмәләр төп игътибарны гаиләгә булышлык итәргә, шул ук вакытта балалар бакчасы учреждениесе челтәрен үстерүгә юнәлтә. Белем бирү спектрларын киңәйтү педагогик процесска яңа формалар кертүгә юнәлтелгән. Заманча белем бирү учреждениесе үстерешле тирәлекнең үзгәрүчән шартларына яраклашкан булырга тиеш.

Балалар бакчасы мәктәпкәчә белем һәм тәрбия бирү өлкәсендә нәтиҗәле эшли торган җирлектә урнашкан. Балалар бакчасының мәктәп белән дәвамчанлык эш планы булдырылган. Үсеш программасынтөзү кирәклеге бакчаның мөмкинлекләреннән һәм тышкы факторларның тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килде.

## III. БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ КОНЦЕПЦИЯСЕ

Балалар бакчасы үсеш концепциясе аның киләчәктә тулы бербөтен система булуын кузаллый. Безнең киләчәк – балаларның аңына салынган белем һәм тәрбия дәрәҗәсенә бәйле. Кем нинди булса, аның дөньясы, эшчәнлеге һәм әйләнә-тирәсе шундый була.

Балалар бакчасының эшчәнлеге түбәндәге **концептуаль идеяләргә** нигезләнә:

- педагогика үсешен балалар бакчасында тормышка ашыру;
- балага шәхес буларак мөнәсәбәт;
- педагогларның иҗади мөстәкыйльлелеге һәм иҗади үсеше;
- дәүләт һәм җәмгыять таләпләренә туры килә торган мәктәпкәчә мәгарифнең яңа заманча сыйфат казанышларына ирешүе;
- дәүләт биргән гарантияләрнең сыйфатлы белемне һәркем ала алырлык дәрәҗәгә җиткерелүе.Үсеш программасы бакчаның эшчәнлегендә төп стратегик нигез булып тора. **Программаның төп максаты** – балаларга өзлексез һәм киңкырлы бербөтен үсеш бирү өчен уңайлыклар тудыру. Программаның эчтәлеге балалар бакчасының актуаль булган үсеш дәрәҗәсенә, коллектив һәм җитәкчелекнең потенциаль мөмкинлекләренә, әти-әниләрнең өметләренә таяна. Идарә итү системасы барлык педагогик процесста катнашучыларны: балалар, педагоглар, администрация, җитәкчелек, әти-әниләрне үз эченә ала.

- **Балалар бакчасы коллективының төп бурычы** – баланың кешелеклелек сыйфатларын тулысынча үстерү һәм киләчәктә үсеш алу өчен әзерлеген формалаштыру.
- **Концепциянең максаты**: балага төрле яклап югары дәрәҗәдә үсеш алу, сәләтләрен ачу һәм үстерү өчен уңай социаль–педагогик шартлар тудыру.
**Концепциянең объекты**: 1.6 -7 яшьлек балалар.
- **Предметы**: педагогик чаралар системасы һәм методлары ярдәмендә төрле эшчәнлектә баланы шәхес буларак үстерү.
- **Балалар бакчасының нәтиҗәлелек күрсәткечләре:**
- - балалар бакчасында психологик яктан уңай климат;
- педагогларга, балаларга, бакчада уңайшартлар тудыру;
- - әти-әниләрнең балалар бакчасына мөнәсәбәте
- **Тикшерү методлары:** мониторинг, әти-әниләргә һәм педагогларга анкеталар уздыру, балаларны күзәтү.

**Белем һәм тәрбия бирү процессының төрле дәрәҗәләрдәге нәтиҗәлелеге**:

- шәхси (баланың шәхси сыйфатлары, кузаллау, ихтияр көче үсеше, аң-белемгә омтылу, иҗатка тартылу көче үсеше);

- мәгълумати (сайланган программа нигезендә).

**МБМБУның төп кыйммәте:**

- бала – уникаль үсешле шәхес;
- педагог - шәхес, белем бирүче;
- максат һәм уңышларга ирешүдә иҗади күмәккоманда составында эш, сыйфатка омтылыш;
- оештыру, узара аралашу культурасы;
- гаилә - баланың үсеше өчен төп мохит, гаилә белән хезмәттәшлек.

**МБМБУ ның вазыйфасы:**

- Һәр балага шәхси якын килеп эшләү.
- Баланың сәламәтлеген саклау һәм ныгыту эшен камилләштерү.
- Гаилә белән тыгыз элемтәдә эшләү.

## IV. МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢҮСЕШ СТРАТЕГИЯСЕ

Балалар бакчасының конкурентлылыгын күтәрү буенча стратегик юнәлешләр:

- Белем бирү процессында яңа шартлар һәм оештыру формалары булдыру (балаларның мөстәкыйль һәм бердәм эшчәнлегенә өстенлек бирелә);
- Практик эштә яңа белем бирү программалары һәм технологияләр куллану (проект эшчәнлеге, информацион технологияләр куллану һ.б.);
- Сәламәтлек саклау эшчәнлеген камилләштерү;
- Мәктәпкәчә мәгарифне информатизацияләү.

**Балалар бакчасының төп юнәлешләре:**

- Сәламәтлек саклау өлкәсе технологияләрен куллануда гаиләнең кыйммәтен формалаштыруда кулланылган алым һәм методларны киңәйтү.

- Компьютер мониторингын уңышлы кертеп, заманча сыйфатлы мәктәпкәчә белем белән тәэмин итү.
- Педагогларның педагогик компетентлылыгын формалаштыру. (белем бирүне информатизацияләү, өйрәтүдә заманча метод һәм алымнарны куллану)
- Овладение педагогическим мониторингом: уточнение критериев оценки образовательной деятельности детей через поэтапное введение интегральной системы оценивания, внедрение современных методик определения результативности воспитания и обучения.
- Повышение профессионального мастерства педагогов на базе детского сада и на курсах повышения квалификации в ИРО РТ г. Казань
- Мәктәпкәчә белем бирүдә вариатив формаларны үстерү.

**Балалар бакчасы эшчәнлегенең төп бурычлары:**

1. Балаларның сәламәтлеген саклауның медик-социаль шартларын оптимальләштерү.

2. Белем бирү процессын эчтәлекне, шартларны, мәгариф һәм тәрбия технологияләрен модернизацияләү юлы белән яңарту.

3. Педагогларның һөнәри компетентлыгын һәм инновацион культурасын камилләштерү.

4. Оптимальләштерү системасын идарәсе учреждениедә.

5. Ата-аналарны мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе белән хезмәттәшлеккә җәлеп итүнең яңа оештыру аспектларын эзләү.

6. Мәктәпкәчә белемнең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү.

## V. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ЭТАПЛАРЫ

1 этап **(2016 –2017 гг.)** – Мобилизация- оештыру: булган ресурсларга диагностика уздыру, Программаның төп чараларын барлап чыгу, аларны тормышка ашыру өчен тиешле шартлар тудыру, Программаны үтәргә керешү.

2нче этап **(2017 –2018)** – Эксперт – тикшерү: Программаның стратегик мәсьәләләрен тормышка ашыру.

3нче этап**(2018-2019)** – гомумиләштерү – йомгаклау: йомгак ясау һәм эшчәнлек нәтиҗәләрен Программаны тормышка ашыруның төп юнәлешләре буенча максатлары һәм бурычларына тәңгәл килүен карау, нәтиҗәләрне игълан итү һәм алдагы чор өчен Үсеш Программасы булдыру.

## VI. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ ЭШЧӘНЛЕГЕ ПЛАНЫ(ПРОЕКТЛАР)

| **Проект** | Үсеш юнәлеше | Тормышка ашыру вакыты | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Эчтәлеге | 2016–2017 | 2017–2018 | 2018–2019 | 2019–2020 | 2020–2021 |
| **1** | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **Программа, методика, технологияләр белән тәэмин ителеше.** | Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын ФДББС таләпләренә нигезләнеп төзү һәм кулланылышка кертү. Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү һәм өстәмә программаларны яңарту. Проект эшчәнлеген кертү. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны ике дәүләт телен өйрәтүгә юнәлтелгән УМК материалларын белем һәм тәрбия процессына кертү. Балаларга ике дәүләт телен өйрәтү процессын УМК материаллары нигезендә, тормышка ашыру. | * * * * | * * * * | * * * | * * * | * * * |
| **2.Мәктәпкәчә мәгарифне информатизация-ләштерү** | Белем бирү һәм идарә итү процессына информацион технологияләр кертү. | * | * | * | * | * |
| **3. Сәламәтлек саклау технологияләре** | МБМБУның педагогик процессына сәламәтлек саклау технологияләрекертү. | * | * | * | * | * |
| **4. Белем бирү процессының куркынычсызлыгы** | Материаль-техник базаны ныгыту. | * | * | * | * | * |
| **5. Кадрлар сәясәте.** | Педагогларның һөнәри осталыкларын күтәрү. | * | * | * | * | * |

**VI.1.** Проект 1.**Программа, методика, технологияләр белән тәэмин ителеш.**

Балалар бакчасында белем бирү процессының эчтәлеге балаларның психофизик үсеш һәм мөмкинлекләреннән чыгып, федераль дәүләт таләпләре нигезендә төзелгән, кулланылышка кертелгән төп гомуми белем бирү программасыннан чыгып билгеләнә.

Проблема: Педагогларны балаларның бердәм һәм мөстәкыйль эшчәнлегенә өстенлек бирүгә юнәлдерү, бу проблеманы хәл итү максатыннан инновацион программалар һәм технологияләр куллану.

Максат: Балалар бакчасы педагогларын проект технологияләренә өйрәтү һәм проект эшчәнлегендә эти-әниләрне катнаштыру.

Бурычлар:

1. Педагогларны балаларның бердәм һәм мөстәкыйль эшчәнлегенә өстенлек бирүгә юнәлдерү, проект эшчәнлегенә эти-әниләрне тарту максатыннан, яңа алымнар кулланырга өйрәтү. Проект эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатыннан методик ярдәм оештыру.

2. Әти-әниләрне информация белән даими тәэмин итеп торып, баланың индивидуаль белем үзләштерү маршрутын төзүгә катнаштыру.

3. Проект эшчәнлегенә мәктәпкәчә яшьтәге балаларны җәлеп итү максатыннан социаль партнерлыкны киң җәелдерү.

4. Интернет челтәре аша балалар бакчасы партнерлары белән эффектив хезмәттәшлек оештыру.

| | Проект чаралары | Этаплар, үтәлү вакыты | Проектны гамәлгә ашыру өчен чыганаклар, формалар, механизмнар, материаль һәм хезмәт ресурслары турында мәгълүмат | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Финанс чыганаклары | Башкаручылар |
| **1** | Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын ФДББС таләпләренә нигезләнеп төзү. | 2016-2017 | - | Иҗади төркем |
| **2** | Контроль һәм мониторинг системасын төзү һәм апробацияләү. | 2016 | - | Мөдир тәрбиячеләр |
| **3** | Төп гомуми белем бирү программасын практикада куллануһәм төзәтмәләр кертү | 2016-2017 | - | Мөдир тәрбиячеләр |
| **4** | Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны ике дәүләт телен өйрәтүгә юнәлтелгән УМК материалларын өйрәнү | 2016 | - | Мөдир тәрбиячеләр |
| **5** | Семинар-практикум «ФДББС нигезендә бердәм белем бирү эшчәнлеген интегральләштерүдә кулланылган УМК» | 2016 | - | Мөдир тәрбиячеләр |
| **6** | Педсовет: «Мультимедиа чаралары кулланып, балаларның сөйләм телен үстерү » | 2017 | - | Мөдир тәрбиячеләр |
| **7** | Ата-аналар өчен практикум “Проектларны тормышка ашыруда ата-аналарның катнашы» | 2016 | - | Мөдир тәрбиячеләр |
| **8** | Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү һәм өстәмә программаларга яңалык кертү | 2016-2019 | - | Мөдир тәрбиячеләр |

**Көтелгән нәтиҗә:**

- белем һәм тәрбия бирү процессын оештыру шартларын оптимальләштерү (үстерешле тирәлек, методик ярдәм һ.б.);
- балалар бакчасы белән идарә итү сыйфатын яхшырту;
- педагогларның профессиональ осталыклары эффектив эш формалары һәм алымнары куллану нәтиҗәсендә югары дәрәҗәгә күтәрелү;
- белем һәм тәрбия бирү процессын ФДББС таләпләренә, Н.Е. Веракса, Т.С. Комарова. М.А. Васильева редакциясендә төзелгән «От рождения до школы» программасына нигезләнеп төзү.
- педагогларның укыту-методик комплектлар белән эшләү алымнарын һәм ысулларын тулысынча үзләштерүе.
- Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ике дәүләт телендә иркен аралашу өчен уңай шартлар тудыру

**Социаль нәтиҗә:**

- Әти-әниләрне балалалары белән гаиләдә узара аралашырга өйрәту.

## **VI.2**. 2-нче проект. **Мәктәпкәчә мәгарифне информатизацияләштерү**

Проблема:Шәхескә юнәлтелгән белем бирүне тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү һәм педагогик эшчәнлектә күп санлы мәгълуматларны өйрәнү зарур. Әлеге проблеманы тормышка ашыруда компьютер технологияләренең ролен бәяләп бетермәү.

Максат**:**ИКТ технологияләрне куллануда педагогларның профессиональ осталыкларын югары дәрәҗәгә кутәрелүенә ирешү;

Бурычлар:

1. Әти-әниләрне информация белән даими тәэмин итеп торып, баланың индивидуаль белем үзләштерү маршрутын төзүгә катнаштыру.

2. Интернет челтәре аша эффектив хезмәттәшлек оештыру.

3. ИКТ технологияләр буенча муниципаль һәм региональ конференцияләрдә катнашу.

| № | Проект чаралары | Этаплар, үтәлү вакыты | Проектны гамәлгә ашыру өчен чыганаклар, формалар, механизмнар, материаль һәм хезмәт ресурслары турында мәгълүмат | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Финанс чыганаклары | Башкаручылар |
| **1.** | ИКТ технологияләрен белем бирү процессына гамәлгә кертү | 2016 | - | Мөдир тәрбиячеләр |
| **2.** | Балалар бакчасы сайтында электрон форматта документларны булдыру. | 2016-2018 | | Мөдир тәрбиячеләр |
| **3.** | Педагогларның квалификациясенкүтәрү | 2016-2019 | Бюджеттарафыннан | Мөдир тәрбиячеләр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **4.** | Интернет челтәре аша эффектив хезмәттәшлек оештыру | 2016-2019 | Бюджеттарафынн ан | Мөдир тәрбиячеләр |
| **5.** | Кирәкле җиһазлар белән педагогларны тәэмин итү: компьютерлар, интерактив такталар | 2016-2019 | Бюджет тарафыннан | Мөдир |
| **6.** | Бакча сайтын даими тулыландырып тору. | 2016-2019 | - | Мөдир тәрбияче |

## Көтелгән нәтиҗә:

- Белем бирү процессында педагогларның ИКТ технологияләр белән эшләү белемнәрен югары дәрәҗәгә җиткерү.
- Педагогларның компетентлылык дәрәҗәсен күтәрү һәм укыту-методик материалларны тиешле күләмдә булдыру.
- Балалар бакчасының материаль-техник базасын ныгыту һәм тулыландыру.
- Белем бирү эшчәнлегенең сыйфатын яхшырту һәм эш тәҗрибәсе белән уртаклашу.
- Әти-әниләрне балалар бакчасының эшчәнлеге, баланың уңышлары, казанышлары белән даими таныштыру.

## **VI.3**. 3 нче проект.**Сәламәтлек . Сәламәтлек саклау технологияләре.**

Һәр җәмгыятьнең иминлеге үсеп килүче буынның сәламәт булуына бәйле. Сәламәт буын формалаштыру – илебезнең иң төп стратегия мәсьәләләрнең берсе. Балалар бакчасында педагоглар белем бирү эшчәнлеген балаларның сәламәтлек дәрәҗәләрен исәпкә алып төзиләр. Яна Иглай балалар бакчасының төп бурычларның берсе булып балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм психик үсеше өчен мөмкинлекләр тудыру тора.

«Белем бирү сыйфаты» категориясе «сәламәтлек» категориясе (баланың физик, психик һәм социаль иминлеге) белән тыгыз бәйләнештә тора, ягъни танып белү процессы баланың сәламәтлегенә тискәре йогынты ясарга тиеш түгел, бигрәк тә психик яктан.

Иске Кади балалар бакчасында балаларның сәламәтлеге өлкәсендә уңай динамика күзәтелә.

Проблема:Еш авыручы балаларның саны арту санитар-гигиена, профилактика һәм сәламәтләндерү чараларын көчәйтүне таләп итә.

Максат:Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәламәтлеген ныгыту һәм сәламәт яшәү рәвешенә күнектерү.

Әти-әниләрнең һәм хезмәткәрләрнең, сәламәт яшәү рәвеше алып бару һәм сәламәт бала тәрбияләү максатыннан, медицина, психология, педагогика өлкәсендә белемнәрен арттыру.

Бурычлар:

1. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, сәламәт яшәү рәвешенә күнектерү.

2. Балалар бакчасының сәламәтлек саклау эшчәнлеге сыйфаты буенча мониторинг ясау.

3. Әти-әниләрнең сәламәт яшәү рәвеше алып бару һәм сәламәт бала тәрбияләү өчен медицина, психология, педагогика өлкәсендә белемнәрен арттыру.

| № п/п | Мероприятие | Этаплар | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
| **1** | Балалар бакчасының сәламәтлек саклау эшчәнлеге сыйфаты буенча мониторинг программасын төзү. | 2016-2019 | Финансланма ган | Мөдир |
| **2** | Балалар бакчасының сәламәтләндерү һәм дәвалау-профилактик эшенең торышына бәя бирү. | 2016-2019 | Финансланма ган | Мөдир тәрбиячеләр |
| **3** | Балалар бакчасында физкультура-сәламәтләндерү эшен камилләштерү өчен яңа шартлар тудыру<br>- СанПиН һәм төп гомуми белем бирү программасы таләпләренә җавап бирә торган җиһазлар булдыру,<br>- проект эшчәнлеге. | 2016-2019 | Финансланма ган | Мөдир |
| **4** | Балалар бакчасының һәм әти-әниләрнең сәламәтлек саклау эшчәнлеген гомумиләштерү һәм тәҗрибәләрен тарату:<br>- информационбюллетеньнәрчыгару;<br>- методик берләшмәләрдә катнашу | 2016-2018 | Финансланма ган | Мөдир тәрбиячеләр |

## Көтелгән нәтиҗә:

- Балаларның авыру очракларын киметү максатыннан сәламәт яшәү рәвешенә күнектерү.
- Балалар бакчасының сәламәтлек саклау эшчәнлеге сыйфаты буенча ел саен мониторинг үткәрү.
- Әти-әниләрнең сәламәт яшәү рәвеше алып бару һәм сәламәт бала тәрбияләү өчен медицина, психология, педагогика өлкәсендә белемнәрен арттыру.
- Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның эмоциональ һәм психик яктан иминлеген тәэмин итү өчен мөмкинлекләр тудыру.
- Балаларның бакчага йөрешен арттыру.

## Социаль нәтиҗә:

- Гаиләдә сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен уңай мотивация формалаштыру.
- Сәламәт яшәү рәвеше эшчәнлеге буенча педагогларның профессиональ дәрәҗәләрен күтәрү.
- Педагогик тәҗрибә тарату.

## **VI.4**. 4 нче проект.**Белем бирү процессының куркынычсызлыгы.**

Проблема:
-Финанс ресурсларының җитмәүчелеге;
- эти-әниләр тарафыннан балаларның куркынычсызлыгы мәсьәләләрен хәл итү буенча түбән әзерлеге.

Максат:

Материаль-техник базаны яхшы тоту, оешма мөлкәте белән нәтиҗәле идарә итү.

Бурычлар:

1.Белем биру процессындакатнашучыларның сәламәтлеген һәм тормыш иминлеген тәэмин итү.
2.Бакча бинасын санитария-гигиена нормаларына һәм куркынычсызлык таләпләренә туры китерү.

| № | Чаралар | Этаплары | Проектны тормышка ашыруда хезмәт һәм материаль ресурсларны тарту механизмы, чыганаклар, формалар турында белешмә | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Финанс чыганаклары | Башкаручылар |
| **1** | Группа бүлмәләрен ремонтлау | 2016-2021 | Бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар | мөдир |
| **2** | Балалар мәйданчыгын җиһазлау | 2016-2021 | Бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар | мөдир |

**Көтелгән нәтиҗә:**---ремонтланган группа бүлмәләре
--ремонтланган балалар мәйданчыгы

**Социаль нәтиҗә:**-Белем биру процессындакатнашучыларның сәламәтлеген һәм тормыш иминлеген тәэмин итү.
-Район куләмендә балалар бакчасының дәрәҗәсен арттыру.

## **VI.5.** нче проект**Кадрлар сәясәте**

Бугенге көндә Яна Иглай балалар бакчасында кадрлар белән тәэмин ителеш 100 процент тәшкил итә. Педагогик персонал махсус белемле хезмәткәрләрдән тора.

Коллектив бердәм, тату, тырыш, алдынгы карашлы, мәктәпкәчә мәгарифтәге катлаулы мәсьәләләрне хәл итүгә һәм уңай эш нәтиҗәсенә ирешүгә юнәлтелгән. Педагогик коллективның иҗади потенциалы дәрәҗәсен билгеләү анализы педагогларның профессиональ осталыкларының күтәрелүен, педагогик инновацияләрне үзләштерү, гамәлгә кертү, үз эшчәнлекләренә дөрес бәя бирү һәм мәктәпкәчә белем бирүнең төрле өлкәләрендә эш тәҗрибәләрен уңышлы таратуын күрсәтә.

Проблема:Балалар бакчасының педагогик процессны оештыруга, белем бирү программаларына таләпләренең тамырдан үзгәрүе, мәгълүматларның төгәл һәм җитешле булмавы, белем һәм эш тәҗрибәләрнең җитмәве зур кыенлыклар тудыра.

Максат:Заманча белем бирү эшчәнлеген оештыру процессында педагогларның белемнәрен киңәйтү, тирәнәйтү һәм көндәлек практикада куллану.

Бурычлар:

1.ФДББС таянып, яңа УМКны кулланып,балаларга белем бирү эшчәнлеген камилләштерү
2. Педагогларның профессиональ эш тәҗрибәсен баету, аларның креатив сәләтләрен үстерү.
3. Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә педагогларның квалификациясен күтәрүне оештыру.
4. Педагогларның район һәм республика күләмендә төрле дәрәҗәдәге бәйгеләрдә катнашу өчен мөмкинлекләр үстерү.

| № | Проект чаралары | Этаплары үтәү срогы | Проектны тормышка ашыруда хезмәт һәм материаль ресурсларны тарту механизмы, чыганаклар, формалар турында белешмә | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Финанс чыганаклары | Башкаручылар |
| **1.** | Мәктәпкәчә мәгарифне модернизацияләүгә кагылышлы норматив документлар белән танышу. | 2016 | Финансланмый | Мөдир тәрбиячеләр |
| **2.** | Педагогларны, заманча технологияләр ярдәмендә, өлкәннәр һәм балалар арасындагы узара мөнәсәбәтләрне аңларга өйрәтү(проекттехнологияләре, информацион технологияләр,УМК) | 2016-2021 | Финансланмый | Мөдир тәрбиячеләр |
| **3.** | УМК куллану буенча мастер-класслар оештыру | 2016-2021 | Финансланмый | Мөдир тәрбиячеләр |
| **4.** | Педагогик һәм җитәкче кадрларның профессиональ эшчәнлек сыйфатын өйрәнү | 2016-2021 | Финансланмый | Мөдир тәрбиячеләр |
| **5.** | Педагогларның квалификацияләрен күтәрүбуенча перспектив планнар төзү | 2016-2021 | Финансланмый Финансланмый | Мөдир тәрбиячеләр |
| **6.** | Педагогик һәм җитәкче кадрларга аттестация әзерләү һәм үткәрү. | 2016-2021 | Финансланмый | Мөдир тәрбиячеләр |

## Көтелгән нәтиҗә:

Педагогларның замана таләпләре нигезендә практик эшчәнлектә креативлыкка әзер булуы.
Педагогларның квалификацияләрен күтәрү буенча индивидуаль перспектив планнар.

## Социаль нәтиҗә:

Педагогларныңкомпетентлылык дәрәҗәләрен күтәрү.
Конкурс хәрәкәтендә хезмәткәрләрнең актив катнашуы ярдәмендә баланың белем сыйфатын яхшырту.

Коллективта кадрларның күчеш проценты кимүе.

## VI.6.Мәктәпкәчә белем бирү оешмасын тәмамлаучының социаль портреты

1. Физик яктан үскән, төп культура-гигиена күнекмәләрен үзләштергән.Бала гармонияле физик үсешнең мөмкин булган иң зур дәрәҗәсенә ирешкән (шәхси мөмкинлекләрен исәпкә алып).
Аның төп физик сыйфатлары һәм актив хәрәкәт итү ихтыяҗы формалашкан. Үз яшенә туры килгән гигиена процедураларын мөстәкыйль башкара, сәламәт яшәү рәвешенең иң гади кагыйдәләрен үти.

2.Кызыксынучан, актив.Әйләнә-тирәдәге (предметлар һәм әйберләр дөньясындагы, мөнәсәбәтләр дөньясындагы һәм үзенең эчке дөньясындагы) яңа билгесез әйберләр һ. б. белән кызыксына. Өлкәннәргә сораулар бирә, экспериментлар ясарга ярата. Мөстәкыйль эш итә ала (көндәлек тормышта, бала эшчәнлегенең күптөрле төрләрендә). Авырсынган очракларда өлкәннәрдән ярдәм сорый. Белем бирү процессында зур кызыксыну белән, актив катнаша.

3. Хисчән, кеше хәленә керә белүче.Якын кешеләренең һәм дусларының хисләренә җавап бирә. Әкият, тарих, хикәяләрнең персонажларын кызгана, хәлләрен аңлый. Сынлы сәнгать әсәрләренә, музыкаль һәм әдәби әсәрләргә, табигать дөньясына хис-тойгылы мөнәсәбәт күрсәтә.

4.Өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән аралашу чараларын һәм үзара мөгаләмә ысулларын үзләштергән.Бала вербаль һәм вербаль булмаган аралашу чараларын бердәй куллана, әңгәмә кора белә, өлкәннәр һәм балалар белән үзара мөгаләмәнең конструктив ысулларын файдалана белә (килешә, предметлар алмаша, хезмәттәшлек иткәндә эшләрен бүлешә). Өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән сөйләшкәндә, ситуациягә карап, сөйләшү стилен үзгәртә ала.

5. Беренчел әһәмиятле күзаллаулар нигезендә үзенең тәртибе белән идарә итә ала һәм үз эш-гамәлләрен планлаштыра белә, гомуми кабул ителгән элементар нормаларны һәм үз-үзен тоту кагыйдәләрен үти.Баланың тәртибе минутлык теләк һәм ихтыяҗ белән түгел, ә өлкәннәр тарафыннан куелган таләпләр һәм «нәрсә ул яхшы, нәрсә ул начар» дигән беренчел әһәмиятле күзаллаулар (мәсәлән, сугышырга, кечеләрне кыерсытырга, әләкләшергә ярамый; булганың белән уртаклашырга, өлкәннәрне хөрмәт итәргә кирәк һ. б.) белән билгеләнә. Билгеле бер максатка ирешүгә юнәлтелгән эш-гамәлләрен планлаштыра ала. Урамда юл йөрү кагыйдәләре, җәмәгать урыннарында (транспортта, кибеттә, даруханәдә, театрда һ. б.да) үз-үзен тоту кагыйдәләрен үти.

6.Яшенә ярашлы интеллектуаль һәм шәхси мәсьәләләрне чишәргә сәләтле.Бала мөстәкыйль үзләштергән белемнәрен һәм эшчәнлек ысулларын яңа мәсьәләләр (проблемалар) чишүдә куллана ала; ситуациягә карап, мәсьәләне (проблеманы) чишү ысулын үзгәртә белә. Ул үзенең уйлаганын тәкъдим итә ала һәм аны рәсемдә, төзүдә, сөйләмдә һ. б. да тасвирлый белә.

7.Үзе, гаиләсе, җәмгыять (якын-тирә социум), дәүләт (ил), дөнья һәм табигать турында беренчел күзаллаулары бар.Бала күзаллый:
– үзе турында, үзенең һәм башка кешеләрнең билгеле бер женестә булуы турында;
– гаилә составы, туганлык мөнәсәбәтләре һәм үзара бәйләнеш, гаилә вазифаларын бүлешү, гаилә гореф-гадәтләре (традицияләре) турында;

– җәмгыять (якын-тирә социум), аның мәдәни кыйммәтләре һәм җәмгыятьтә үзе тоткан урын турында;
– дәүләт (шулай ук аның символлары, «кече» һәм «зур» Ватан, аның табигате ) һәм үзенең аның бер өлеше булуы турында;

**Балалар бакчасы педагогы моделе**Балалар бакчасының төп максат, бурычларын эш юнәлешләрен анализлап, киләчәктәге педагог моделен билгеләргә була:

**1. Педагогның профессиональлелеге:**

- тиешле педагогик һәм психологик яктан әзер;
- норматив документлар таләпләреннән чыгып эшли белү өчен тиешле белем һәм осталык нигезләренә ия;
- укыту һәм тәрбия, сәламәтлек саклау процессының заманча психолого-педагогик концепцияләрендәиркен ориентлаша, аларга үзенең педагогик эшчәнлегендә нигезләнә;
- эшне планлаштыру һәм балаларның белем дәрәҗәсен бәяләү осталыгына ия;
- педагог, шәхескә юнәлтелгән белем бирү моделенә таянып, балаларның игътибарын педагогик биремнәрне эшләргә юнәлтә;
- педагогик эшчәнлектә кызыксынып һәм иҗади якын килеп эшли;
- Белем һәм тәрбия бирү процессында техник чараларны һәм ИКТ технологияләрне уңышлы файдалана;
- Бердәм эшчәнлек вакытында балаларның активлыгын, кызыксынучанлыкларын. белемгә омтылышларын стимуллаштыра;

**2. Педагогның шәхси сыйфатлары:**

- заманча мәктәпкәчә мәгариф алдында торган максат-бурычларны төгәл кузаллый;
- җәмгыятьнең мораль нормаларына каршы килми торган, тормышка уңай карашлы шәхес;
- Баланың хәленә керә белүче, тактлы, кайгыртучан, сизгер, шәфкатьле;
- педагогик тактлы, үзенең шәхсән дәрәҗәсен саклый белә, балаларны, әти-әниләрне, коллективны хөрмәт итә;
- Белем һәм тәрбия бирүдә булган уңышларын һәм уңышсызлыкларын, җитешсезлекләрен, ялгышларын фикерләп анализлый белә;
- креатив карашлы;
- педагогик процесста гуманизация идеяләрентормышка ашыра;

| | | |
|---|---|---|
| Размещение информации на информационных стендах | Информация о режиме работы специалистов, фамилия, имя, отчество специалистов, основные услуги учреждения, порядок приёма в учреждение, порядок подачи жалоб и предложений. | По мере изменения данных |

Прошито и пронумеровано и скреплено печатью 22 листа(ов).

Должность,

ФИО ________________

________________ (подпись)

« ___ » ________ 20 ___ года

М.П.